**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-11-59

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-11-59

**2025елның 7 феврале** **4номер**

# КАРАР

**«Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында".**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 14 декабрендәге 28/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең тормыш эшчәнлеге, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен уңай шартларга кеше хокукларын үтәү максатларында, карар бирәм:

1. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә: :

1.1. Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Столбище авылы, Поперечная урамы адресы буенча урнашкан, кадастр номеры 16:24:150201:4379 булган җир кишәрлегендә «Сәүдә объектлары» шартлы рөхсәт ителгән төренә «кибетләр" урнаштыру рөхсәт ителгән файдалану төре

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты да: 2025 елның 6 марты, башлана 9:30

2.2. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище АҖ башкарма комитеты бинасы: 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет ур., 103 й.

2.3. 2.3. Югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризаларны түбәндәге адрес буенча урнашкан Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга: 422616, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Столбище авылы, Совет ур., 103 йорт.

2.4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2025 елның 5 мартына кадәр.

3. Әлеге карарны "Кама ягы" («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми

порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **А.А. Абдрәфиев**